ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

26.12.2020 г. № 126

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Баш-Башлыгының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Түбән Кама муниципаль районы идарәче кадрлары резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибен камилләштерү максатларында, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының «Түбән Кама муниципаль районы идарәче кадрлары резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 20 февралендәге 3 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар белән расланган Түбән Кама муниципаль районы идарәче кадрлары резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә (1 нче кушымта):

10 пунктның «д» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр»;

16 пунктка түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «, баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә»;

32 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «, комиссиянең чираттагы утырышында кабул ителә торган»;

1.2. Карар белән расланган Түбән Кама муниципаль районының идарәче кадрлары резервын формалаштыру комиссиясе составын (2 нче кушымта) әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының «Түбән Кама муниципаль районы идарәче кадрлары резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 20 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 22 мартындагы 9 номерлы карары белән расланган идарәче кадрлар резервына кандидатларның законнарны белүләрен бәяләү комиссиясе составында:

комиссия составыннан Әкбәрова Әлфия Гомәр кызын чыгарырга;

комиссия составына Түбән Кама муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте һәм персонал белән идарә итү бүлеге җитәкчесе Ворошилова Марина Валентиновнаны комиссия секретаре итеп кертергә;

Зарифуллин Рөстәм Таһир улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Түбән Кама муниципаль районы Советының хокук бүлеге җитәкчесе».

2. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгының «Түбән Кама муниципаль районы идарәче кадрлары резервың формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 20 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган 2 нче кушымтаның үз көчен югалтуын таныrга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе А.Р. Сафинга йөкләргә.

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044867

А.Р. Метшин

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгының
2020 елның «26» 12
126 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
идарәче кадрлары резервын формалаштыру буенча
комиссия составы

| | |
|---|---|
| Сафин<br>Артур Рафис улы | - Түбән Кама муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Ворошилова<br>Марина Валентиновна | - кадрлар сәясәте һәм персонал белән идарә итү бүлеге җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Шаһиволиева<br>Римма Мәснәви кызы | - кадрлар сәясәте һәм персонал белән идарә итү бүлеге җитәкчесе урынбасары, комиссия секретаре; |
| Баһманов<br>Хәмзә Әзәл улы | - Түбән Кама муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча); |
| Умников<br>Александр Витальевич | - Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Камелина<br>Марина Валерьевна | - Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары; |
| Бәдретдинов<br>Илнар Наил улы | - Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Зарифуллин<br>Рөстәм Таһир улы | - Түбән Кама муниципаль районы Советының хокук бүлеге җитәкчесе; |
| Рамазанова<br>Айзирәк Рәмзин кызы | - Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары. |